| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.01.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 39** |

2016 елда Зеленодольск муниципаль районында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлек уставының 44 статьясындагы 8 пункты, 48 статьясындагы 8 пункты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елга Зеленодольск муниципаль районында җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыру өчен махсус вәкаләтле җирле үзидарә органнарын, бюджет учреждениеләрен һәм вазыйфаи затларны кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Зеленодольск муниципаль районында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән җирле үзидарәнең махсус вәкаләтле органнарына, бюджет учреждениеләренә һәм вазыйфаи затларга:

2.1. дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән бюджет акчаларын тиешенчә исәпкә алуны тәэмин итәргә;

2.2. максатчан билгеләнеше буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән матди бюджет акчаларын кулланыну тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты 2016 елның 13 гыйнварындагы 39 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга махсус вәкаләтле затлар исемлеге**

| Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләре (өлкәләр буенча) | Дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында ТР законнары | Вәкаләтле муниципаль органнар, учреждениеләр (субвенцияләр алучылар) | Вәкаләтле вазыйфаи затлар, тикшереп торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар |
|---|---|---|---|
| Җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләре | 2005 елның 22 декабрендәге 132 номерлы Татарстан Республикасы законы | "Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе | "Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе |
| Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2005 елның 30 декабрендәге 143 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары-мәгариф идарәсе башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе |
| Административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2005 елның 30 декабрендәге 144 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (террорчылыкка һәм экстремизмга, гражданнар оборонасына, мобилизациягә, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мәгълүматлаштыруга каршы тору мәсьәләләре), Зеленодольск муниципаль районының административ комиссиясе рәисе |
| Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре | 2005 елның 30 декабрендәге 146 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе (субвенцияләрне исәпләү өлешендә), Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр , опека һәм попечительлек), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы, «Зеленодольск муниципаль районы Финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары җитәкчеләре |
| Мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2006 елның 22 февралендәге 15 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары-мәгариф идарәсе башлыгы |
| Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2006 елның 7 апрелендәге 29 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе башлыгы |
| Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру | 2006 елның 11 декабрендәге 78 номерлы Татарстан Республикасы законы | «Зеленодольск муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы» муниципаль | "Зеленодольск муниципаль районы Финанс – бюджет палатасы" муниципаль учреждениесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| буенча дәүләт вәкаләтләре | | учреждениесе (субвенцияләрне исәпләү өлешендә), Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары | җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары җитәкчеләре |
| Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2007 елның 27 декабрендәге 66 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ | «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре: йогышлы авырулар булган учакларда, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яисә таралу өчен шартлар булган һәм сакланып кала торган территорияләрдә һәм урыннарда дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, лаборатор тикшеренү ысулларын кулланып уздырыла торган санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне оештыру | 2006 елның 16 мартындагы 19 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек) |
| Архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2007 елның 24 декабрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (икътисади һәм финанс анализы), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы |
| Опека һәм попечительлек | 2008 елның 20 мартындагы | Зеленодольск муниципаль районы | Зеленодольск муниципаль районы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 7 номерлы Татарстан Республикасы законы | Башкарма комитеты | Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы |
| Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләре | 2010 елның 30 июлендәге 60 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (террорчылыкка һәм экстремизмга, гражданнар оборонасына, мобилизациягә, мәгълүматлаштыруга каршы тору мәсьәләләре) |
| Хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре:<br>1) Себер яраксыз үләт базларын һәм биотермик чокырларны тоту, шул исәптән аларны төзеклэндерү, гамәлдәге законнар нигезендә тиешле санитар халәткә китерү;<br>2) объектларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрү;<br>3) биотермик чокырларны консервацияләү<br>4) күзәтүчесез хайваннарны тоту;<br>5) күзәтүчесез хайваннарны вакытлыча тоту пунктында тоту;<br>6) күзәтүчесез хайваннар санын (күзәтүчесез хайваннарны | 2012 елның 13 гыйнварындагы 9 номерлы, 2013 елның 20 маендагы 39 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты " МБУ | «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| стерильләштерү (кастрацияләү), аеруча агрессив күзәтүчесез хайваннарны үлгән, аларда авырулар, кеше һәм хайваннар өчен гомуми, яки артык газаплар тудыра торган, дәваланмый торган авыруларны) җайга салу | | | |
| Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча дәүләт вәкаләтләре | 2015 елның 3 ноябрендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, "Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» МБУ | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» МБУ җитәкчесе |
| Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча дәүләт вәкаләтләре муниципаль район составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, аларда җир биләмәләреннән файдалану һәм җир төзү кагыйдәләре расланган, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бирү вәкаләтләреннән тыш дәүләт вәкаләтләре | 2015 елның 26 декабрендәге 109 номерлы Татарстан Республикасы законы | “Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" муниципаль учреждениесе | "Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" муниципаль учреждениесе җитәкчесе |